СОВЕТ УТЯШКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Центральная, д.10,
с. Татарское Утяшкино, 423186

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ӘДӘМСӘ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Үзәк урамы, 10
Әдәмсә авылы, 423186

Ut.Nsm@tatar.ru тел.: (8-84348) 3-47-41, факс: (8-84348) 3-47-65,

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль берәмлеге
Әдәмсә авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2025 елның 30 декабреннән № 4-16

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 7.11.2014 елның 41-107 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешләренә үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларының (закон актларының аерым нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 28 ноябрендәге 425-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Әдәмсә авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 7.11.2014 елның 41-107 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлеге Советының 23.03.2015 елның 49-125а номерлы, 29.09.2015 елның 2-7 номерлы, 12.11.2018 елгы карарлары редакциясендә) кертергә 48-102, 24.09.2019 № 57-125; 20.03.2021 № 10-29;) (алга таба – карар) түбәндәге үзгәрешләр:

1.1. карарның 2 пунктындагы 4 пунктчасында «300 миллион сум» сүзләреннән соң: « проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төзелеп бетмәгән объектлардан тыш» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» нда бастырып чыгарырга: https://pravo.tatarstan.ru «Интернет» мәгълүмат - телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https:// novosheshminsk.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлеге Советының Законлылык, җирдән файдалану һәм территорияне төзекләндерү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Әдәмсә авыл җирлеге башлыгы А.И. Назмутдинова